Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының
бишенче чакырылышының дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

4 декабрь, 2025 ел № 22

2025 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2025 елда Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлап, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматны 2025 елда игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы муниципаль милкен нәтиҗәле исәпкә алу һәм аңа идарә итү максатларында:

- Питрәч муниципаль районының берләштерелгән бюджетына муниципаль мөлкәттән, шул исәптән җир ресурсларыннан файдаланудан керемнәр керүнең айлык мониторингын тәэмин итәргә;
- салым салына торган базаны киңәйтү максатларында теркәлгән хокуклары булмаган күчемсез милек объектларын инвентарьлаштыру эшен дәвам итәргә;
- максатчан билгеләнештә файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен әйләнешкә кертү эшен дәвам итәргә;
- күпбалалы гаиләләрне җир кишәрлекләре белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;
- район учреждениеләренә беркетелгән муниципаль мөлкәтнең сакланышын һәм алардан файдалануын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;
- файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлыгы механизмын, концессия килешүләрен кулланып, хуҗалык әйләнешенә җәлеп итәргә;
- файдалануга тапшырыла торган объектларны муниципаль милеккә һәм район учреждениеләренә үз вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов